ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2024 ел Баулы шәһәре №120

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 ноябрендәге 207 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына гариза кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына өстәмә кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 173-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 ноябрендәге 207 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына гариза кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 27 февралендәге 55 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге өстәмә кертергә:

3 бүлектә «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, үз эченә алган вариантлары.»:

3.6. пунктны 3.6.3.4. пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«3.6.3.4. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, мөрәҗәгать итүче булып торучы балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкилнең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булган очракта) күрсәтә, шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров